**Татарстан Республикасы**
**Алабуга муниципаль районы**
**«2 нче гимназия» муниципаль бюджет**
**гомуми белем бирү учреждениесе**

“2 нче татар гимназия”се үз эшен 1992 нче елның август аенда башлап җибәрде. 2008 елда Алабуга муниципаль районының «2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе итеп үзгәртелде. 2022 нче елның августында гимназия үзенең 30 еллык юбилеен билгеләп үтте.

Бүгенге көндә гимназия ике бинада урнашкан. Беренчесе – Тугаров урамы, 6 нчы йорт. Бу бина 1888 нче елда Кама төбәгендә икмәк белән эш итүче 1 нче гильдия сәүдәгәрләре аталы-уллы Федор Прохор улы һәм Прохор Федор улы Гирбасовлар төзеп, өч класслы Шәһәр училищесы булган.

Икенче бина Тойма урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан. Бу йортта 1914 нче елдан бирле федераль казначейлык булган.

**Уку йортының юридик һәм фактик адресы:**

1 нче бина: 423600, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Тугаров урамы, 6 нчы йорт;

2 нче бина: 423600, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Тойма урамы, 2 нче йорт.

Телефоны: +7(855)-577-83-19;

E-mail: G2.Elb@tatar.ru





Сәлахов Ильяс Рәхимҗан улы 1961 нче елның 1 нче декабрендә Әлмәт районының Түбән Абдул авылында туа. 1985-1990 нчы елларда Алабуга дәүләт педагогия институтының гомуми техник фәннәр факультетында укый. 1992-1998 нче елларда Алабуга шәһәренең 2 нче татар гимназиясендә директор вазифасын башкара. Хәзерге вакытта - педагогика фәннәре кандидаты, доцент, профессор.

1998-2002 нче елларда 2 нче татар гимназиясен Гыйльфанов Зиннур Нуриәхмәт улы җитәкли.



2002-2010 нчы елларда - Сафиуллина Лилия Миргасим кызы.

2010-2014 нче елларда - Галиев Аяз Миргасим улы.

2015 нче елда - Сафина Миңнечулпан Наил кызы.

2016-2018 нче елларда - Адиятуллин Илсур Илдан улы.

2018 нче елдан Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «2 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен Аиров Рамил Равил улы җитәкли.

**Гимназияне ачуда һәм аның үсешендә зур өлеш керткән җәмәгать эшлеклеләре**

2 нче татар гимназиясен ачуда Әгъзамов Миңнеәхмәт Хуҗа улы җитәкчелегендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый үзәгенең Алабуга филиалы, Алабуга дәүләт педагогия институнының өлкән укытучысы, татар иҗтимагый үзәге җитәкчесе Шәрипова Тәскирә Бари кызы, Алабуга шәһәре башлыгы урынбасары (соңыннан башлыгы) Ишков Илдар Наил улы, «ЕлАЗ» җитештерү берләшмәсе генераль директоры Зарипов Равил Хаммат улы актив катнаштылар.

**Гимназиянең төп эш юнәлешләре:**

укучыларга карата:

- чыгарылыш сыйныф укучыларын гаилә һәм җәмгыять тормышына әзерләү, профильле укыту кертү, укучыларда фәнгә карата кызыксыну уяту;
- сәләтле балалар белән эшләү, сәләтле балаларның интеллектуаль потенциалын, иҗади сәләтләрен һәм шәхси сыйфатларын үстерү буенча эш системасын булдыру (укучыларның фәнни-гамәли конференцияләрдә, семинарларда, олимпиадаларда, бәйгеләрдә, ярышларда катнашуы);
- «Гимназистлар сәламәтлеге», «ГРИНПИС» экологик программасы, патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия программасы нигезендә сәламәт яшәү рәвеше, экологик, интеллектуаль, патриотик үзаң тәрбияләү буенча эшчәнлек.

Укытучылар күмәклегенә карата:

- педагогларның квалификациясен күтәрү, методик эшне үстерү, укыту-тәрбия процессына заманча белем бирү технологияләрен кертү;

- социаль мохиткә карата – гимназиянең имиджын формалаштыру;

Белем бирү процессын тәэмин итүгә карата:

- гимназиядә укыту-тәрбия процессының матди-техник яктан тәэмин ителешен яхшырту;

- Алабуга муниципаль районы "2 нче балалар музыка мәктәбе", “1 нче балалар сәнгать мәктәбе" өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениеләре эшчәнлеге.

## Дәрестән тыш эшчәнлек

2 нче гимназия базасында түбәндәге түгәрәкләр эшли:

- “Татар сөйләм культурасы” (җитәкчесе - Низамова Н.Б.);
- “Татар халкының милли бизәкләре” (җитәкчесе – Зинатуллина Э.Р.);
- “Я лидер” (җитәкчесе – Кузнецова Ю.П.);
- “Юнармия” (җитәкчесе – Гарифуллин Р.И.);
- “Шахмат” (җитәкчесе – Валиханов И.Р.);
- “Ритмика” түгәрәге (җитәкчесе – Машанова А.В.).

Шунысы куандыра: гимназиядә КДН һәм ПДН да исәптә торучы укучылар юк.

**Традицион эш-гамәлләр:**

төрле фәннәр буенча олимпиадалар, фән атналыклары, “Белем бәйрәме”, "Үзидарә көне", "Сөмбелә", "Нәүрүз", “Соңгы кыңгырау”, "Сабантуй" бәйрәмнәре, “Гимназия гүзәле”, “Карга боткасы" һәм башкалар.

## Өстәмә мәгълүмат

2001 нче елда гимназиядә патриотик тәрбия бирү буенча Маһинур Фәйзуллина исемендәге тарихи-әдәби музей ачылды. Ул хәзергәчә тәрбия үзәге булып тора. Музейның еш кунаклары - республиканың һәм шәһәрнең танылган фән эшлеклеләре, сугыш һәм хезмәт ветераннары.